**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.05.2014 № 1011

**г. Казань**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 22.07.2013 елгы 1330нчы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актын закончылыкка туры китерү максатында б о е р а м:

1. «Дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында конкурс үткәрү турындагы» Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 22.07.2013 елгы 1330нчы боерыгына (алга таба - боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерыкның 4нче пунктын түбәндәге редакциядә язарга:

«4. «Дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында конкурс үткәрү турындагы» Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 27.12.2006 елгы 1225нче боерыгын көчен югалткан дип танырга»;

Боерык белән расланган, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга конкурс үткәрү турындагы Положениедә (алга таба - Положение):

2.3 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә язарга:

«2.3. Конкурс комиссиясенең сәркатибе комиссиянең эшләвен тәэмин итә (теркәү, гаризаларны кабул итү, делоларны формалаштыру, комиссиянең протоколларын алып бару һәм комиссиянең эшчәнлеген тәэмин итүче башка йөкләмәләрне үтәү)»;

2.4 пунктын түбәндәге редакциядә язарга:

«2.4. Конкурс комиссиясенең составына министр һәм (яисә) аның тарафыннан вәкаләт бирелгән гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт хезмәте һәм кадрлар сораулары буенча бүлекчәдән, юридик (хокукый) бүлекчәдән һәм

гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга конкурс үткәрелә торган бүлекчәдән), Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, шулай ук Министрның соравы буенча Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан бәйсез экспертлар – гражданлык хезмәте белән бәйле булган сораулар буенча белгечләр буларак чакырылучы (экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә) фән, белем бирү һәм башка оешмаларның вәкилләре керәләр.

Министрлыкта вакант вазыйфага урнашуга конкурс комиссиясенең составына Министрлык карамагындагы Җәмәгатьчелек советы вәкиле керә.

Бу вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән бер өлешеннән дә ким булмаска тиеш»;

2.11 пунктын түбәндәге редакциядә язарга:

«2.11. Конкурс комиссиясенең карары кандидат булмаганда кабул ителә һәм аны гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасына урнаштыру өчен яисә урнашуны кире кагу өчен нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе шулай ук гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашу конкурсын җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында рекомендация характерында булган карарны кабул итәргә хаклы»;

3.2 пунктын түбәндәге редакциядә язарга:

«3.2. Конкурста катнашу өчен документлар Министрлык сайтында, шулай ук «Интернет» мәгълүматый-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүматый системасының сайтында аларны кабул итү турында белдерүне куюю көненнән башлап 21 көн эчендә кандидатлар тарафыннан конкурс комиссиясенә тапшырыла (Положениенең 4нче кушымтасы)»;

3.3 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә язарга:

«3.3. Документларны нигезле сәбәп аркасында вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда Министр аларны кабул итү срокларын күчерергә хаклы»;

4.4 пунктының 4.4.1 подпунктын түбәндәге редакциядә язарга:

«4.4.1 Беренче этапта Министрлык сайтында, шулай ук «Интернет» мәгълүматый-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүматый системасының сайтында конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турында белдерү, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла: гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасы исеме, бу вазыйфага

урнашу өчен дәгъвачыга куелган таләпләр, гражданлык хезмәте үтүнең шартлары, конкурс комиссиясенә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, документлар кабул ителә торган срок, конкурсның ниятләнелүче үткәрелү вакыты, аны үткәрүнең вакыты һәм тәртибе, шулай ук конкурс турында тулы мәгълүматның чыганаклары турында мәгълүматлар (телефон, факс, электрон почта, Министрлык сайтының электрон адресы, документларны кабул итү өчен җаваплы булган шәхеснең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)»;

4.10 пунктын түбәндәге редакциядә язып бирергә:

«4.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасына конкурсның җиңүчесен урнаштыру турындагы Министрлык боерыгы басыла, һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Конкурс комиссиясе тарафыннан гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасына урнашуга үткәрелгән конкурсны җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында рекомендация характерында булган карар кабул ителгән очракта, гражданин ризалыгы белән, аны, гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасына туры килүче шул ук группаның гражданлык хезмәтенең вазыйфаларына урнашу өчен, Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында Министрлыкның боерыгы басыла.

Шуның белән бергә, вазыйфалар номенклатурасына туры китереп, конкурсның җиңүчесен вазыйфага билгеләүгә тәкъдим итү вакытында, Министрга мәҗбүри тәртиптә конкурс комиссиясенең карары һәм Конкурс комиссиясенең шундый карар кабул итүе өчен нигез булып торган материаллар бирелә»;

Положениенең 4нче кушымтасының 4 һәм 5 пунктларын түбәндәге редакциядә язарга:

«4. Конкурста катнашу өчен гражданин түбәндәге документларны тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) үз кулы белән тутырылган һәм кул куелган анкета (фотографиясен теркәп), аның формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы боерыгы белән расланган »;

в) паспортның яисә аны алмаштыручы документның күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч үз кулы белән бирелә);

г) тиешле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (искәрмә булып хезмәт эшчәнлегенең беренче тапкыр башкарылуы тора), нотариус аркылы яисә эш (хезмәт) урыны буенча

кадрлар хезмәте белән расланган, яисә гражданинның эш (хезмәт) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

белем һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук, гражданинның теләге буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация бирелүне яисә аны арттыруны раслаучы документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турындагы нотариус аркылы яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган документларның күчермәләре;

д) гражданинда гражданлык хезмәтенә урнашуга яисә аны үтүгә киртә булучы авыруларның булмавы турында медицина йомгаклавы (001 -ГС/у формасы);

е) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турындагы законнчылыгы белән каралган башка документлар.

5. Конкурста катнашу өчен Министрлыкның гражданлык хезмәткәре шәхси гариза бирә.

Конкурста катнашырга теләген белдергән башка төрле дәүләт органының гражданлык хезмәткәре түбәндәге документарны тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) үз кулы белән тутырылган, кул куелган һәм гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәтенең вазыйфасы урынына калган дәүләт органының кадрлар хезмәте белән расланган анкета (фотографиясен теркәп). Анкетаның формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы боерыгы белән расланган»;

боерыкның 2нче кушымтасында:

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә язарга:

«1.2. Гражданинга (гражданлык хезмәткәренә) конкурста катнашырга түбәндәге очракта рөхсәт ителми:

1) аны законлы көчкә кергән суд карары белән эшкә яраксыз яисә чикләнгән эшкә яраклы дип тану;

2) аның дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфасы буенча хезмәт вазыйфаларын үтәү мөмкинлегенә юл куймаучы законлы көчкә кергән суд хөкеме буенча җәзага тартылганы, шулай ук федераль закон белән урнаштырылган тәртиптә кире алынмаган яисә капланмаган хөкемгә тартылганы булу;

3) гражданин урнашырга теләгән гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча, яисә гражданлык хезмәткәре урнашкан гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча хезмәт вазыйфаларын үтәү шундый мәгълүматларны куллану белән бәйле булган очракта, дәүләт серен яисә федераль закон тарафыннан сакланылучы башка серне тәшкил

итүче мәгълүматларны куллануга рөхсәт кәгазен рәсмиләштерү процедурасын үтүдән баш тарту;

4) аның гражданлык хезмәтенә урнашуга яисә аны үтүгә киртә булып торучы һәм медицина оешмасы йомгаклавы тарафыннан расланган авыруы булу;

5) гражданлык хезмәткәре белән якын туганлык (ата-аналары, ире белән хатыны, абыйлары, апалары, уллары, кызлары, шулай ук ир белән хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары һәм балалары), әгәр гражданлык хезмәте вазыйфасына урнашу бер-берсенә турыдан-туры буйсыну белән бәйле яисә алар бер-берсенең тикшерүе астында булса;

6) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу яисә бүтән илнең гражданлыгын алу;

7) башка илнең (башка илләрнең) гражданлыгы булу, әгәр бүтәне Россия Федерациясенең халыкара килешүе тарафыннан каралмаган булса;

8) гражданлык хезмәтенә эшкә кергәндә ялган документлар яисә билгеле ялган мәгълүматлар тапшыру;

9) гражданлык хезмәтенә эшкә кергәндә 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында»гы Федераль закон тарафыннан билгеләнгән мәгълүматларны тапшырмау яисә керемнәре, милке һәм милкенә бәйле булган йөкләмәләре турында билгеле ялган мәгълүматлар тапшыру;

10) чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгать низагларын булдырмау яисә аларны бетерү турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында»гы Федераль закон һәм башка федераль законнар тарафыннан коррупциягә каршылык күрсәтү максатларында билгеләнгән вазыйфаларны үтәмәгән очракларда эшкә алучының вәкиленең гражданлык хезмәткәренә ышанычын югалтуы;

11) хәрби хезмәткә алу комиссиясе йомгаклавына туры китереп, законлы нигезләр булмаган килеш, аны, чакыру буенча хәрби хезмәтне үтмәгән, дип тану (искәрмә булып контракт буенча хәрби хезмәт үткән гражданнар тора). »;

2.1 пунктын түбәндәге редакциядә язарга:

«2.1. Белем буенча һәм гражданлык хезмәте стажы яисә эш стажы (тәҗрибәсе) буенча квалификация таләпләре.

Гражданлык хезмәте вазыйфаларының бөтен группаларының «җитәкчеләр», «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)», «белгечләр» категорияләренә, шулай ук гражданлык хезмәте вазыйфаларының төп һәм әйдәүче группаларының «тәэмин итүче белгечләр»

категориясенә гражданлык хезмәте вазыйфаларының квалификация таләпләре исәбенә югары белемнең булуы кирә.

Гражданлык хезмәте вазыйфаларының бөтен группаларының «җитәкчеләр», «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)», «белгечләр» категорияләренә, шулай ук гражданлык хезмәте вазыйфаларының төп һәм әйдәүче группаларының «тәэмин итүче белгечләр» категориясенә гражданлык хезмәте вазыйфаларының квалификация таләпләре исәбенә эшчәнлек юнәлешенә туры килүче урта һөнәри белемнең булуы кирә.

Гражданлык хезмәте стажына яисә белгечлек буенча, гражданлык хезмәткәрләре өчен хәзерлек юнәлеше буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

гражданлык хезмәте вазыйфаларының төп группасының бөтен категорияләренең гражданлык хезмәте вазыйфаларына урнашу өчен - әйдәүче яисә өлкән группаның гражданлык хезмәте вазыйфаларында ике елдан да ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча өч елдан да ким булмаган хезмәт стажы булу;

гражданлык хезмәте вазыйфаларының әйдәүче группасының бөтен категорияләренең гражданлык хезмәте вазыйфаларына урнашу өчен - өлкән яисә кече группаның гражданлык хезмәте вазыйфаларында бер елдан да ким булмаган гражданлык хезмәте стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан да ким булмаган хезмәт стажы булу;

Гражданлык хезмәте стажына яисә белгечлек, гражданлык хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече группаларының гражданлык хезмәте вазыйфаларына урнашу өчен әзерлек юнәлеше буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) квалификация таләпләре билгеләнми.

Гражданлык хезмәте стажын билгеләгән вакытта шулай ук тиешле вазыйфа группаларының федераль дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларындагы һәм аларга тиңләштерелгән хәрби һәм хокук саклау хезмәте вазыйфаларындагы, шулай ук тиешле вазыйфа группаларының муниципаль хезмәт вазыйфаларындагы эш стажы да исәпләнә»;

боерыкның 3нче кушымтасын түбәндәге редакциядә язарга:

«Гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тапшырылучы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфаларына урнашуга документларның һәм материалларның исемлеге

Конкурста катнашу өчен Россия Федерациясе гражданины түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхси гариза;

2) үз кулы белән тутырылган һәм кул куелган анкета (фотографиясен теркәп), аның формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы боерыгы белән расланган;

3) паспортның яисә аны алмаштыручы документның күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч үз кулы белән бирелә);

4) тиешле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (искәрмә булып хезмәт эшчәнлегенең беренче тапкыр башкарылуы тора), нотариус аркылы яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган, яисә гражданинның эш (хезмәт) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

белем һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук, гражданинның теләге буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация бирелүне яисә аны арттыруны раслаучы документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турындагы нотариус аркылы яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган документларның күчермәләре;

5) гражданинда гражданлык хезмәтенә урнашуга яисә аны үтүгә киртә булучы авыруларның булмавы турында медицина йомгаклавы (001 -ГС/у формасы);

6) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турындагы закончылыгы белән каралган башка документлар.

Конкурста катнашу өчен Министрлыкның гражданлык хезмәткәре шәхси гариза тапшыра.

Конкурста катнашырга теләк белдергән башка төрле дәүләт органының гражданлык хезмәткәре түбәндәге документларны тапшыра:

а) шәхси гариза;

б) үз кулы белән тутырылган, кул куелган һәм гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәтенең вазыйфасы урынына калган дәүләт органының кадрлар хезмәте белән расланган анкета (фотографиясен теркәп). Анкетаның формасы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы боерыгы белән расланган».

2. Боерыкның үтәлүен тикшерүне үз өстемдә калдырам.

Министр

А.Ю. Вафин

В.С.Семенова, (843) 231-79-15